**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты карары**

**25.01.2018 ел** **№ 65**

**2013-2016 елларга Кама Тамагы муниципаль районы буенча гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы программага үзгәрешләр кертү хакында**

2007 елның 21июлендәге 185 –ФЗ номерлы “Торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштырырга ярдәм итүче Фонд турындагы” федераль закон нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2013-2016 елларга Кама Тамагы муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы программага Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 11 сентябрендәге “Кама Тамагы муниципаль районы буенча 2013-2016 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы программасын раслау турындагы” 760 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.Карарның атамасында һәм бөтен текст буенча “2013-2016 елларга” сүзләрен “2013-2017 елларга” сүзләре белән алыштырырга.

1.2.Программа паспортының “Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары” бүлегендәге “32,4” цифрасын “32 239 809,27”гә, “6,14”не “5 015 261,33”кә, “38,38”не “37 255 070,60” цифраларына алыштырырга.

1.3. Программа паспортының IV бүлегенең 1 абзацында “38,38” цифрасын “37 255 070,60”ка, “32,4”не “32 239 809,27”гә, “6,14”не “5 015 261,33” цифраларына алыштырырга.

1.4. Программа паспортының IV бүлегенең 3 абзацында “32 465,03” цифрасын “30 646,16” цифрасына алыштырырга.

1.5. 2013-2016 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаның 1,2.3 номерлы кушымталарына үзгәрешләр кертеп, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының шушы карарының 1,2,3 номерлары кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче в.б.** **Р.В.Михеев**